Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Бәйрәкәтамак торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№10 19 ноябрь 2024 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Бәйрәкәтамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышы һәм махсус хәрби операция катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- Бәйрәкәтамак торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерүгә (контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Бәйрәкәтамак торак пунктының Яңа урамы буенча юл урамнары челтәрен норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, салу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));

- Бәйрәкәтамак торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү) юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында эләргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әгълиева